Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районының
Ленино-Кокушкино авыл җирлеге

## Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районының Ленино-Кокушкино авыл җирлегенең Олы Бутырка торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында КАРАР

18 ноябрь, 2020 ел № 1

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Ленино-Кокушкино авыл җирлегенең Олы Бутырка торак пункты гражданнарының 2020 елның 18 ноябрендәге җыены беркетмәсе нигезендә түбәндәгеләр ачыкланды:

- җыенны уздыру өчен билгеләнгән территориядә яшәүче һәм гражданнар җыенында катнашырга хокуклы гражданнар саны 157 (йөз илле җиде).
- халык җыены эшендә катнашкан гражданнарның гомуми саны 87 (сиксән җиде).
- гражданнар җыенына кертелгән мәсьәләгә «**РИЗА**» өчен гомуми сан 79 (җитмеш тугыз).
- гражданнар җыенына кертелгән мәсьәләгә «**КАРШЫ**» өчен гомуми сан 8 (сигез).

Югарыда бәян ителгәннәрдән чыгып түбәндәге карар кабул ителде:

1. «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» гы 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25 статьясындагы 6 өлеше нигезендә **гражданнар җыены мәсьәләсе буенча карарын**, түбәндәге мәсьәлә буенча « Сез 2021 елда Олы Бутырка торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә, 1 төркем инвалидларын бер тапкыр бирелә торган түләүләрдән (үзара салымнан) азат итеп, һәм җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны алдагы эшләрне башкару өчен куллану белән килешәсезме?:

- авыл эчендәге юлларны ремонтлау»

**кабул ителгән дип санарга.**

2. Әлеге карарны «Вперёд» («Алга») газетасында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru), Питрәч муниципаль районының рәсми сайтында (www.pestreci.tatarstan.ru) һәм Ленино-Кокушкино авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында да бастырып чыгарырга (халыкка игълан итәргә).

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан (халыкка игълан ителгән) көненнән үз көченә керә.

Ленино-Кокушкино авыл җирлеге башлыгы А.Р. Сәйфетдинов